КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 9 сентябрь г.Казань № 754

2025 елга, 2026 һәм 2027 еллар план чорына Татарстан Республикасында балаларның һәм яшьләрнең ялын оештыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтүгә норматив чыгымнарны раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Түбәндәгеләрне расларга:

карарга теркәлгән 2025 елга, 2026 һәм 2027 еллар план чорына Татарстан Республикасында балаларның һәм яшьләрнең ялын оештыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтүгә норматив чыгымнарны;

2025 елга, 2026 һәм 2027 еллар план чорына Татарстан Республикасында балалар һәм яшьләр ялын оештыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтүне тәэмин итүгә норматив чыгымнарны муниципаль һәм дәүләт оешмалары, шулай ук муниципаль берәмлек территориясендә урнашкан коммерциягә караган һәм коммерциягә карамаган оешмалар (муниципаль һәм дәүләт оешмаларыннан тыш) хезмәткәрләре балалары арасыннан 7 яшьтән 18 яшькә кадәрге хезмәт күрсәтүне бер алучыга 51,9 сум күләмендә.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2024 – 2026 елларга Татарстан Республикасында балаларның һәм яшьләрнең ялын оештыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтүгә норматив чыгымнарны раслау турында» 2023 ел, 8 сентябрь, 1110 нчы карары үз көчен югалткан дип танырга.

3. Бу карар 2025 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

2025 елга, 2026 һәм 2027 еллар план чорына Татарстан Республикасында балаларның һәм яшьләрнең ялын оештыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтүгә норматив чыгымнар

| Дәүләт хезмәте исеме, балаларның һәм яшьләрнең ялын оештыру формасы | | Норматив чыгымнар көненә 1 ятак-урынга, сум | | |
|---|---|---|---|---|
| | | 2025 ел | 2026 ел | 2027 ел |
| Татарстан Республикасында балаларның һәм яшьләрнең ялын оештыру | Шәһәр яны ял лагерендагы смена | 1 274,8 | 1 343,41 | 1 425,66 |
| | Шәһәр яны ял лагерендагы юнәлешле смена һәм төрле тематик юнәлештәге смена | 1 223,2 | 1 282,88 | 1 355,27 |
| | Палатка тибындагы лагерьдагы смена | 1 650,07 | 1 760,21 | 1 888,66 |
| | Белем бирү оешмалары тарафыннан оештырылган көндезге лагердагы, хезмәт һәм ял лагерендагы смена | 259,48 | 270,96 | 283,0 |
| | Югары белем бирүче мәгариф оешмалары студентлары өчен физкультура-сәламәтләндерү чаралары | 236,89 | 246,37 | 256,22 |
| | Шифаханә-курорт оешмаларындагы смена | 1 683,91 | 1 743,75 | 1 816,3 |
| | Кара диңгез яры буендагы шәһәр яны ял лагерендагы юнәлешле смена һәм төрле тематик юнәлештәге смена | 2 920,73 | 3 055,97 | 3 220,92 |